# БЕЛДЕРҮ

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасы һәм 39.18 статьясы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы түбәндәге характеристикалы җир кишәрлеген 20 елга арендага бирү турында хәбәр итә:

Кадастр номеры 16:23:070502:445, мәйданы 1810 кв.м, җир категориясе: «торак пунктлар җирләре», рөхсәт ителгән файдалану төре: «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» (Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматлар нигезендә), кишәрлекнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Зур Кукмара авыл җирлеге, Янсыбы авылы, Пионер урамы, 13а.

Җир кишәрлегенә карата хокуклар чикләнә (күчемсез милеккә чикләнгән хокук). Мондый чикләүләр (чикләнгән хокук) әлеге хәбәргә кушымта итеп бирелгән Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан җир кишәрлегенә карата өземтәдә күрсәтелгән.

Югарыда күрсәтелгән җир кишәрлеген арендага алырга кызыксынучы гражданнар аукционда катнашу нияте турында әлеге хәбәр басылып чыкканнан соң 30 көн эчендә бирергә хокуклы. Гаризаны гариза бирүче (гариза бирүченең ышанычлы заты) эш көннәрендә (дүшәмбе – җомга, эшләми торган бәйрәм көннәреннән, эшләми торган көннәр дип игълан ителгән көннәрдән, ял көннәре күчерелгән көннәрдән тыш) 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән сәгать 13.00 гә кадәр – төшке аш өчен тәнәфес белән) Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 йорт, 101 нче бүлмәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшыра ала. Гариза һәм аңа кушылган документларны электрон документ формасында тапшырганда, гариза бирүче (гариза бирүченең ышанычлы кешесе) Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең территориянең кадастр планында урнашу схемасын раслау турында гаризалар, дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сату буенча аукцион яки дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза, дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза, дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеге бирү турында гариза, һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен, шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гаризаларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, электрон документлар формасында бирү тәртибен һәм ысулларын, шулай ук аларның форматына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 14 гыйнварындагы 7 номерлы боерыгы таләпләрен үтәүне, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гаризаны һәм башка документларны имзалауны (раслау) тәэмин итә.

Гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы – 2024 елның 02 мае, 15 сәгать 00 минут.